# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«11» 03 2025 ел Яр Чаллы № 757

«Муниципаль милектәге җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (срогы чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2021 елның 26 октябрендәге 3783 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 34 статьясы 7 өлеше үз көчен югалтуын тану хакында» 2022 елның 07 октябрендәге 385-ФЗ номерлы Федераль закон, «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәмне киңәйтү максатында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 03 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (срогы чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2021 елның 26 октябрендәге 3783 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.3.3.4 пунктына түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«Регламентның 3.3.3.1, 3.3.3.3 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында илкүләм пространство белешмәләре системасы эшчәнлеген тәэмин итүче федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

2) 3.4.5 пунктына түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«Регламентның 3.4.2, 3.4.4, 3.4.5 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында илкүләм пространство белешмәләре системасы эшчәнлеген тәэмин итүче федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

3) 3.5.6 пунктының икенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Регламентның 3.5.3 - 3.5.5 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында илкүләм пространство белешмәләре системасы эшчәнлеген тәэмин итүче федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.

Регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь срогы 14 эш көне тәшкил итә, җир кишәрлеген бирү турында хәбәрнамә басылып чыккан очракта – 47 эш көне.»;

4) 3.6.2 пунктының дүртенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Процедураларны үтәү, техник мөмкинлекләр булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Процедураларны, шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле процедураларны үтәү кысаларында илкүләм пространство белешмәләре системасы эшчәнлеген тәэмин итүче федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев